1САНЛЫ ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ
28 ноябрь 2021 ел

2021 елның 28 нояберендэ Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Чыпчык авыл җирлеге Яңа Бөреле пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законының 35 статьясы нигезендә, 2021 елның 28нояберендэ 13 сәгать 00 минутта уздырылган “Сез 2022 елда Чыпчык авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?” дигән мәсьәлә буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде:

) Яна Бөреле торак пунктында урамны яктыртуы

2) Яна Бөреле торак пунктында Яшел урам һәм Малмыж-Казан юлы киселешендәге яңгыр сулары торбасын урнаштыру

Аерым мәсьәләләр буенча экономия булган очракта Чыпчык авыл җирлеге Башкарма комитетына акчаларны, җыен белән билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә рөхсәт итәргә

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:
Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 48 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 26 кеше, бу 54,1%ны тәшкил итә.
тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:
“Риза” позициясе өчен гражданнар җыенында 26 катнашучы тавыш бирде; “Каршы” позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.
Бәян ителгәннәрдән чыгып, гражданнар җыены түбәндәгечә хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Чыпчык авыл җирлеге Яңа Бөреле торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

“Сез 2022 елда Чыпчык авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?” дигән мәсьәлә буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде:

1)Яна Бөреле торак пунктында урамны яктыртуы

2) Яна Бөреле торак пунктында Яшел урам һәм Малмыж-Казан юлы киселешендәге яңгыр сулары торбасын урнаштыру

Аерым мәсьәләләр буенча экономия булган очракта Чыпчык авыл җирлеге Башкарма комитетына акчаларны, җыен белән билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә рөхсәт итәргә- дигән мәсьәлә буенча карарны кабул ителгән дип санарга.

2. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда, Биектау муниципаль районы рәсми сайтында авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Чыпчык авыл җирлеге башлыгы И.Р.Җиһаншин